ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№391 от «08» 11 2022 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 19 июнендәге
387 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең ихтыярыйлык (волонтерлык) мәсьәләләре буенча аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 5 февралендәге №15-ФЗ Федераль законы, «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы №135-ФЗ Федераль законның 17.3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 июнендәге «Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылары, ихтыярый (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге Тәртибен раслау турында» 387 нче карарга ( алга таба –Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарга Кушымтаның 3 пунктында:

1) дүртенче абзацта «күрсәтү» сүзен «гадәттән тыш хәлләрне бетерүдә һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдә, янгыннарны сүндерүдә, һәлакәттән коткару эшләрендә катнашу» сүзләренә алмаштырырга.

2) Түбәндәге эчтәлектәге «гражданнарның хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашуы» дигән абзац өстәргә;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов

0000011462